| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕЦИЛЬНИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Зур Чынлы авылы

РЕШЕНИЕ КАРАР

13 марта 2025 ел № 48/1

"Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»карар проекты турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Уставының 32 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, Татар транспорт прокуратурасының 25.02.2025 ел №23/1-2-2025 протестын, Чүпрәле районы прокуратурасының 06.03.2025 ел № 02-08-02-2025 протестын исәпкә алып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба – текст буенча-кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Советының 06.09.2017 ел, № 20/1 карары (Советның 2018 елның 22.03.2018 ел № 29/1, 29.10.2021 ел, №12/1,07.04.2022 ел №17/1, 29.08.2022 № 20/2 карарлары белән расланган үзгәрешләр белән), кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

3. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Зур Чынлы авылы, Ватан урамы, 1 нче йорт һәм Зур Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 15 апрелендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Зур Чынлы авылы, Ватан урамы, 1 йорт Зур Чынлы авылы мәдәният йортының актлар залында билгеләргә.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (иҗтимагый фикер

алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июнендәге 9/1 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Нигезләмә нигезендә уздырыла.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлеге Советының 20.12.2013 № 33/2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Тәртип нигезендә үткәрелә.

6. Әлеге проект буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2025 нче елның 14 апреленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Чүпрәле районы, Зур Чынлы  авылы, Ватан  урамы, 1 нче йорт.

7. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы  авыл җирлеге Советына карауга кертергә тиеш

8. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә кергән нигезләмәләрдән тыш, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми халыкка хәбәр итү һәм урнаштыру көнендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Зур Чынлы
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Җ.Фатхуллов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле
муниципаль районы
Зур Чынлы
авыл җирлеге
Советының 13.03.2025 ел
№48/1 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр

1) **35 пунктның 35.11 пунктчасында** «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) **37 пунктның 5 пунктчасында** «һәм тимер юл " сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 65, 66, 67 пунктларда «(тимер юл)» сүзен төшереп калдырырга.

4) **185 пунктны** төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Зур Чынлы
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ж.Фатхуллов